| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>СОВЕТ ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ |
|---|---|

КАРАР
№ 5

КАРАР
21 апрель 2022ел

**«Янурыс авыл җирлеге территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыю һәм чыгару тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Сарман муниципаль районының 2007 елның 5 маендагы 11 номерлы Янурыс авыл җирлеге карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда контрольдә тоту чараларын үткәргәндә үтәлергә тиешле мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларының һәм аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2020 елның 11 июлендәге 1036 номерлы карары нигезендә, Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Янурыс авыл җирлеге советы раслаган «Янурыс авыл җирлеге территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыю һәм чыгару тәртибе турында» 2007 елның 5 маендагы 11 номерлы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Тәртипнең 5.3 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (sarmanovo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге башлыгы А. Ә. Мөхәмәдиева